**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Югары Колчурино авыл жирлегеСоветы**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Совет Верхнеколчуринского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

Адресы: 422873, ТР, Әлки районы, Югары Колчура авылы, Март 8 урамы, 21 йорт

Тел/Факс 8 (84346) 78014

422873, РТ, Алькеевский район, с.Верхнее Колчурино, ул.8 Марта, д.21

Тел/Факс 8 (84346) 78014

**РЕШЕНИЕ** **Югары Колчура авылы** **КАРАР**

2024 елның 22 марты 69 №

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге Советының 2018 елның 14 декабрендәге "Татарстан РеспубликасыӘлкимуниципаль районы Югары Колчура авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында" 34 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2023 елның 12 декабрендәге "Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында" Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 594-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге Советының2018 елның 14 декабрендәге "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында" 34 номерлы карарына (20.03.2019 ел 3№, 12.02.2020 ел 4№, 10.06.2020 ел9№, 30.07.2021 ел21№, 09.02.23 ел 50№, 07.09.2023 ел 54№ карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12) «2007 елның 02 мартындагы Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетада булган белешмәләрнең аңа мәгълүм булган үзгәрешләр турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә язма рәвештә хәбәр итәргә, аларның үзгәрүе яллаучының (эш бирүченең) вәкиле карары буенча булган белешмәләрне исәпкә алмаганда (алга таба - анкетадагы белешмәләр);

6 статьяның 1 пунктның 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны узу чорында ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрнең, тыюларның һәм таләпләрнең үтәлүен раслый торган, яисә

документларны һәм (яисә) белешмәләрне тапшырмаганда, аларны бозган өчен муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү турында таныклый торган алдан ук ялган белешмәләр тапшырылганда;";

14 статьяның 3 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) "2007 елның 02 мартындагы Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкета.

14 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Муниципаль хезмәткә кергәндә әлеге Федераль закон нигезендә граждан тарафыннан тапшырылган белешмәләр (анкетадагы белешмәләрдән тыш) федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерелергә мөмкин. Аерым муниципаль берәмлекләрдә федераль законнар белән муниципаль хезмәткә кергәндә граждан тарафыннан бирелә торган белешмәләрне тикшерүгә өстәмә таләпләр билгеләнергә мөмкин.»;

Әлеге Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 14.1 статья өстәргә:

"14.1 статья. Анкета тапшыру, анкетадагы белешмәләрне үзгәртү турында хәбәр итү һәм мондый белешмәләрне тикшерү

1. Муниципаль хезмәткә кергәндә граждан анкета тәкъдимитә.

2. Муниципаль хезмәткәр язма рәвештә яллаучы (эш бирүчегә) вәкиленә анкетада булган белешмәләрнең мәгълүм үзгәрешләре турында хәбәр итә.

3. Анкетаның рәвеше, шул исәптән аңа кертелә торган белешмәләрнең исемлеге, аларны актуальләштерү тәртибе һәм вакытлары Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә.

4. Анкеттагы белешмәләр яллаучы (эш бирүче) вәкиленең яисә ул вәкаләт биргән затның карары буенча тикшерелергә мөмкин. Анкетадагы белешмәләрне тикшерү гавами хакимият органнарына һәм тиешле мәгълүматка ия оешмаларга, язма рәвештә, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары ярдәмендә, җибәрү юлы белән муниципаль органның кадрлар хезмәте тарафыннан гамәлгә ашырыла. Мәгълүматка ия булган гавами хакимият органнары һәм оешмалар соратып алына торган мәгълүматны соратып алынган гаризаны алган көннән бер айдан да соңга калмыйча бирергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Югары Колчурино авыл җирлегенең мәгълүмат стендында бастырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Әлки муниципаль районы
Югары Колчурино авыл җирлеге
Советы Рәисе Е.В.Краснова